**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 октябрь № 758

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 октябрь, 788 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1055 нче, 2015 ел, 1 апрель, 203 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның бишенче абзацын төшереп калдырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлеге:

| Т/с | Документлар исемлеге | Документлар бирүне | Бирелгән көненнән |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | гамәлгә ашырган оешма | башлап, документның гамәлдә булу вакыты |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Уставның юридик зат җитәкчесе имзасы һәм мөһер белән (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) расланган күчермәсе (булган үзгәрешләре белән) | кече эшмәкәрлек субъекты | кече эшмәкәрлек субъектын бетергәнче |
| 2. | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органы тарафыннан бирелгән юридик затны дәүләт теркәве турында таныклыкның юридик зат җитәкчесе имзасы һәм мөһер белән (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) расланган күчермәсе | кече эшмәкәрлек субъекты | кече эшмәкәрлек субъектын бетергәнче |
| 3. | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органы тарафыннан би-релгән юридик затны са-лым теркәвенә кую ту-рында таныклыкның юри-дик зат җитәкчесе имзасы һәм мөһер белән (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) расланган күчермәсе | кече эшмәкәрлек субъекты | кече эшмәкәрлек субъектын бетергәнче |
| 4. | Юридик затның җитәкчесен билгеләү турында карар /беркетмә/боерыкның юридик зат җитәкчесе имзасы һәм мөһер белән (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) расланган күчермәләре | кече эшмәкәрлек субъекты | чираттагы җитәкчелекне билгеләп куйганчы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 5. | Хуҗалык итүче субъект-ларның статистик регистры составында юридик затның булуы турында мәгълүмат хаты | Федераль дәүләт статистика хезмәте яки аның территори-аль органнары* | 30 көн |
| 6. | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Федераль салым хезмәте яки аның тер-риториаль орган-нары* | 30 көн |
| 7. | Тору урыны бүтән җирдә билгеләнгән җитәкче һәм (яки) хезмәткәр паспор-тының юридик зат җи-тәкчесе имзасы һәм мөһер белән (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгелән-гән очракларда) расланган күчермәсе (хезмәткәрләр яшәр өчен торак урынын файдалануга алырга дәгъва белдерүчеләр өчен) | эшмәкәрлек субъекты | 3 ай |

*Документ ведомствоара электрон багланышлар системасы аша соратып алына яки ирекле файдалана алуда була.»;

8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. «ИТ-парк» ДАУ га хезмәт эшчәнлегенә вазыйфаи аңлатмалар белән билгеләнгән квалификация сыйфатламалары таләпләренә туры килә торган белемнәре булган затлар кабул ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\758.docx